**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.07.2015 Балык Бистәсе штп. № 186пи

Татарстан Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Иминлек Советының һәм Татарстан Республикасында хокук тәртибен тәэмин итү буенча координацион киңәшмәнең 23.04.2015 ел, № ПР-125 киңәйтелгән уртак утырышы беркетмәсен үтәү йөзеннән, «Терроркчылыкка каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты, Россия Федерациясендә үзидарә турында", Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Полиция тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланыуына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлыгы паспортларының формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы белән, кешеләр күпләп була торган урыннарны тикшерү һәм категорияләштерү актлары нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2015 елның 1 июлендәге 186 пи
номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеге

| № п/п | Кешеләр күпләп була торган урынның атамасы | Кешеләр күпләп була торган урын адресы | Кешеләр күпләп була торган урын категориясе |
|---|---|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Ленин ур., 48 | 3 |
| 2 | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Татарстан Республикасының «Балык Бистәсе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Ленин ур., 48А | 3 |
| 3 | Үзәк базарның административ бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, З. Шәймәрданов ур., 73А | 2 |
| 4 | "Чингисхан»офис-сәүдә үзәге бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, З. Шәймәрданов ур., 81Б | 3 |
| 5 | Татарстан Республикасы | 422643, Татарстан | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Балык Бистәсе районының Анатыш авылы Богоявленский чиркәве мәхәлләсе бинасы (Мәскәү патриархаты) | Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,Анатыш ав., Үзәк ур., 37. | |
| 6 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы бистәнең Үзәк мәчете бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Совет ур., 91 | 3 |
| 7 | Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемалар буенча җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен махсус билгеләнгән яисә җайлаштырылган урын Балык Бистәсе ш. т. б. Набережная ур. | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Яр буе ур., | 1 |
| 8 | Бәйрәм чараларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урын («Мәйдан») Балык Бистәсе ш. т. б. Новая урамы (татар халык бәйрәме Сабантуй үткәрү территориясе) | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Яңа ур. | 1 |